ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**«13» июль 2021 ел** **№ 489**

**Үзәкләштерелгән су чыгару системасына һәм чистарту корылмаларына килә торган ташландык суларда пычраткыч матдәләр концентрациясенең мөмкин нормативлары турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Ташландык сулар составын һәм үзлекләрен тикшереп тору кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2020 елның 01 июлендәге 728 номерлы карары үз көченә керүгә бәйле рәвештә, «Су белән тәэмин итү һәм су чыгару турында» 416-ФЗ номерлы Федераль закон, «Салкын су белән тәэмин итү һәм су чыгару кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 29 июлендәге 644 номерлы карары нигезендә, су объектларын пычранудан саклау максатларында, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Үзәкләштерелгән су чыгару системасына һәм «Водоканал-Сервис» ҖЧҖенең чистарту корылмаларына Арча муниципаль районындагы предприятиеләрдән һәм оешмалардан килә торган ташландык суларда пычраткыч матдәләрнең мөмкин булган концентрациясе нормативларын расларга.

Күрсәтелгән нормативлар күпфатирлы йортлар белән идарә итүне гамәлгә ашыра торган оешмаларга (әлеге абонентлардан биологик чистарту

корылмаларына килә торган ташландык суларның иң чик мөмкин булган концентрациясе) кагылмый.

2. "Водоканал-Сервис» ҖЧҖенә Арча шәһәре предприятиеләре һәм оешмалары тарафыннан үзәкләштерелгән су чыгару системасына һәм чистарту корылмаларына агызыла торган ташландык суларның билгеләнгән нормативларга туры килүен даими контрольдә тотуны тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2021 елның 01 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы Р.Р. Фазыловка йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.Р. Мөхәрәмов